СОВЕТ
НАЛАСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Вахитова, д. 64, с.Наласа,
Арский муниципальный район, 422018

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НАЛАСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
М.Вахитов урамы, 64 йорт, Наласа авылы,
Арча муниципаль районы, 422018

Тел. (84366)50-2-25, факс (84366)50-2-25. E-mail: Nalas.Ars@tatar.ru

**Наласа авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**« 20 » апрель 2026 ел** **№16**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Советының “Физик затлар мөлкәтенә салым турында” 2023 елның 29 ноябрендәге 91 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (2024 елның 10 сентябрендәге 108 номерлы, 2025 елның 26 ноябрендәге 7 номерлы үзгәрешләр белән)**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә Наласа авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Советының “Физик затлар мөлкәтенә салым турында” 2023 елның 29 ноябрендәге 91 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә (2024 елның 10 сентябрендәге 108 номерлы, 2025 елның 26 ноябрендәге 7 номерлы үзгәрешләр белән):

1.1. 2нче пунктта:

1.1.1. 5 пунктчаны 7 пунктча дип санарга;

1.1.2. түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә:

«5) түбәндәгегә карата 2 процент:

- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына;

- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына;»;

1.1.3. түбәндәге эчтәлекле 6 пунктча өстәргә:

«6) түбәндәгегә карата 2,5 процент:

- проектлана торган билгеләнеше күпфатирлы йорт булган төзелеп бетмәгән объектлардан тыш, һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата;»;

1.2. 4нче пунктта:

1.2.1. икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. дүрт һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган баласы булган физик затлар (мәгариф оешмаларында көндезге бүлектә белем алучы 23 яшькә кадәрге балалар);»;

1.2.2. өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. мәгариф оешмаларында көндезге бүлектә белем алучы балигъ булмаган балалар һәм 23 яшькә кадәрге балалар, әлеге пунктның 4.1 бүлегендә күрсәтелгән физик затлар.».

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http:arsk.tatarstan.ru) рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Наласа авыл җирлеге башлыгы И.Р.Шакирова

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «НАЛАСИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» СОВЕТ НАЛАСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1609003095